Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Сөләй авыл җирлегенең Шарлама авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

16 ноябрь 2019 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Шарлама авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында” гражданнар җыены хисап комиссиясенең 2019 елның 16 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Шарлама авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Шарлама авылында узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Сөләй авыл җирлегенең Шарлама авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: насос сатып алу өчен» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Шарлама авылы, 1 Май урамы, 26а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

Сөләй авыл җирлеге башлыгы А.З.Бикбаев